КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 12 март г.Казань 150

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын формалаштыру һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2020 ел, 21 декабрь, 1039 нчы карары белән расланган «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын формалаштыру һәм алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын формалаштыру һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2020 ел, 21 ноябрь, 1039 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 21 март, 303 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын формалаштыру һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада:

I бүлектә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бала туу турында акт язуы яисә бала туу турында таныклык реквизитлары.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган белем бирү программасы буенча баланы укытуга һәм (яисә) психолог-медицина-педагогика комиссиясе киңәшләре нигезендә сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучылар, инвалидлар (инвалид балалар) белем алу өчен махсус шартлар тудыруда, ә инвалидлар (инвалид

балалар) өчен шулай ук инвалидны (инвалид баланы) тернәкләндерүнең һәм абилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә ихтыяҗ булу турында белешмәләр.»;

IV бүлектә:

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бала туу турында акт язуы яисә бала туу турында таныклык реквизитлары.»;

түбәндәге эчтәлекле 17 пункт өстәргә:

«17. Мәктәпкәчә белем бирүнең җайлаштырылган белем бирү программасы буенча баланы укытуга ихтыяҗ булу һәм (яисә) сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән укучыларга, инвалидларга (инвалид балаларга) психолАюогия-медицина-педагогика комиссиясе киңәшләре нигезендә белем алу өчен махсус шартлар тудыруга ихтыяҗ булу турындагы белешмәләр, ә инвалид балалар (инвалид балалар) өчен шулай ук инвалидны (инвалид баланы) реабилитацияләүнең индивидуаль программасы нигезендә.».

2. Бу карарның гамәле 2025 елның 1 мартыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын формалаштыру һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2020 ел, 21 декабрь, 1039 нчы карары белән расланган «Электрон балалар бакчасы» автоматлаштырылган мәгълүмат системасын формалаштыру һәм алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында» 2023 ел, 4 апрель, 404 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин